УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел.: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

г. Казань

« 20 » _04____ 2026 г. № 12

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» 01.03.2018 елгы 14 нче номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы Указына туры китерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС Идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында» 01.03.2018 елгы 14 нче номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсенең 07.09.2023 елгы 43 нче номерлы, 28.06.2024 елгы 21 нче номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт хезмәткәрләре хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча ЗАГС идарәсе комиссиясе турында Боерык белән расланган нигезләмәдә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1 Комиссия Идарәнең норматив хокукый акты белән төзелә. Күрсәтелгән акт белән комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм комиссиянең башка әгъзалары раслана. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2.2 нче пунктның «а» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Идарә башлыгы урынбасары (Комиссия рәисе), Идарәнең хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге башлыгы (Комиссия рәисе урынбасары), идарәнең хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), Идарәнең хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенең һәм Идарәнең Идарә башлыгы билгеләгән башка структур бүлекчәләренең Дәүләт хезмәткәрләре (комиссия әгъзалары);»;

2.4 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

3.1 нче пунктның «а» подпунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган Нигезләмәдә каралган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне дөрес булмаган яисә тулы булмаган килеш дәүләт хезмәткәрләренә бирү турында;»;

3.11 пунктның «а» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне дөрес һәм тулы дип билгеләргә;»;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсенең дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Боерык белән расланган Комиссия составында:

И. Ф. Бәдриевны чыгарырга.;

Идарә башлыгы урынбасары, Комиссия рәисе Д.Х. Сәләхетдиновны кертергә.

Идарә җитәкчесе Э.Ф. Әхмәтова